КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1032

2023/2024 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023/2024 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укыту буенча эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022/2023 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын – эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 828 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 сентябрь, 1032 нче
карары белән расланды

2023/2024 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәр өчен һөнәри укыту буенча эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше исеме (белгечлек) | Уку срогы, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгәннәрне һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 5 | 11 601 | 12 979 |
| 43.01.09 | Пешекче, кондитер | 4 | 8 506 | 9 426 |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 7 162 | 7 965 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүенең тракторчы-машинисты | 5 | 12 595 | 14 183 |

______________________________